ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
30.08.2019

г.Мензелинск

**КАРАР**
№ 83

Минзәлә муниципаль район Башлыгының
21.11.2018 елдагы “Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносы турында”гы №119 карарына үзгәрешләр кертү турында

1994 елның 21 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында”гы №68-ФЗ, 1995 елның 22 августындагы “Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручы статусы турында”гы №151-ФЗ Федераль законнары, Татарстан Республикасының 2004 елның 08 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдәр саклау турында”гы №62-ЗРТ Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең бердәм дәүләт системасы турында”гы №794 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 10 ноябрендәге “Татарстан республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасы турында”гы №480 карары нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципальрайон территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү буенча оператив җитәкчелек итү максатларында

КАРАР ЧЫГАРАМ

1. Минзәлә муниципаль район Башлыгының 21.11.2018 елдагы “Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносы турында”гы №119 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. “Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносы турында нигезләмә”нең 1 нче кушымтасында:

а) 6 нчы пунктны түбәндәге эчтәлектәге бишенче һәм алтынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«гражданнар оборонасының көчләрен һәм чараларын гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү буенча чараларны оештыруга һәм уздыруга

җәлеп итү турындагы мәсьәләләрне федераль законда билгеләнгән тәртиптә карау;

гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүне оештыру турында мәсьәләләрне карау";

бишенче абзацны җиденче абзац дип санарга;

б) 8 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Минзәлә муниципаль районы УГЗ" МКУ" – Минзәлә муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте, (алга таба – Минзәлә муниципаль районының БДДХ)";

в) 18 нче пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

г) 19 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гадәттән тыш хәлләр турында, шул исәптән, янгыннар нәтиҗәсендә килеп чыккан хәбәрләрне кабул итү өчен экстрен оператив хезмәтләрне чакыруның "112" бердәм номеры һәм элемтә өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән янгыннар һәм гадәттән тыш хәлләр турында хәбәрләрне кабул итү номеры кулланыла";

д) 28 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Чиктән тыш зарурлык очрагында гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү җитәкчеләре мөстәкыйль карарлар кабул итәргә хокуклы:

эвакуация чараларын уздыру турында;

гадәттән тыш хәлләр зоналарында булган оешмаларның эшчәнлеген туктату турында;

гадәттән тыш хәлләр зоналарында булган оешмаларның объектларында һәм территорияләрендә авария-коткару эшләрен уздыру турында;

гадәттән тыш хәлләр зоналарына халыкны кертүне чикләү турында;

гадәттән тыш хәлләр зоналарында булган оешмаларда гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү өчен матди ресурслар резервларының бронен алу турында;

гадәттән тыш хәлләр зоналарында булган элемтә чараларыннан, транспорт чараларыннан һәм башка милектән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә файдалану турында;

штатта булмаган һәм җәмәгать авария-коткару формированиеләрен, шулай ук күрсәтелгән формированиеләр составына кермәүче коткаручыларны (аларның авария-коткару эшләрен уздыруга аттестация узуын раслаучы документлары булганда) гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү буенча эшләр уздыруга җәлеп итү турында;

халыкны, шулай ук коткаручы булмаган аерым гражданнарны аларның ризалыгы белән кичектергесез эшләрне, авария-коткару эшләрен уздыруга ирекле нигездә җәлеп итү турында;

гадәттән тыш хәлләрнең таралуы һәм аларны ликвидацияләү буенча эш барышы белән бәйле башка кирәкле чаралар кабул итү турында.

Гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү буенча эшләрнең җитәкчеләре чиксез зарурлык килеп туган очракта, үзләре кабул иткән карарлар турында Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга хәбәр итәләр.".

1.2."Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын

тәэмин итү буенча Комиссия составы” 3 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район башлыгының 21.11.2018 елдагы “Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносы турында”гы №119 Минзәлә муниципаль район башлыгының 07.02.2019 №17 карарына үзгәрешләр кертү турында”гы карары.

Минзәлә муниципаль район
Башлыгы А.Ф. Салахов.